**ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 30 октябрь Олы Урсак авылы № 4

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегенең Бушанча авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1.2020 елның 16 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Бушанча авылы, Совет урамы, 32 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Бушанча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- урамдагы яктырткычларны ремонтлау,моның өчен материаллар сатып алу

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

-су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документлар белән рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар);

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

« ӨЧЕН» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Олы Урсак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы Зиннәтуллтин Г.А.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ БОЛЬШЕРУСАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1061673006328
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Большерусаковского сельского поселения
ИНН 1621003084